ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05.04.2021 Казан ш. № 47-1/соц-2021

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2021 елга Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтүне финанслауның җан башына исәпләнгән нормативлары нигезендә социаль хезмәтләргә тарифлар билгеләү турында» 17.12.2020 № 541-5/соц-2020 карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елга Татарстан Республикасының социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында» 2020 елның 30 сентябрендәге 887 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 27 гыйнварындагы 28 номерлы һәм «2021 елга Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының көндезге бүлекчәләрендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында» 2021 елның 12 февралендәге 72 номерлы карарлары кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2021 елга Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтүне финанслауның җан башына исәпләнгән нормативлары нигезендә социаль хезмәтләргә тарифлар билгеләү турында» 17.12.2020 № 541-5/соц-2020 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге карарның 1-4 кушымталарына туры китереп, 2021 елга Татарстан Республикасында социаль хезмәтләрне финанслауның җан башына исәпләнгән нормативлары нигезендә социаль хезмәтләргә тарифлар билгеләргә.»;

1 нче кушымтаның «Җан башына исәпләгәндә социаль хезмәт күрсәтүне финанслау нормативы, сум» дигән таблицасында беренче графада:

«шәһәр» сүзен «шәһәр җирлеге» сүзләренә алмаштырырга;

«авыл» сүзен «авыл җирлеге» сүзләренә алмаштырырга;

2 нче кушымтаның «Җан башына исәпләгәндә социаль хезмәт күрсәтүне финанслау нормативы, сум» дигән таблицасында беренче графада:

«шәһәр» сүзен «шәһәр җирлеге» сүзләренә алмаштырырга;

«авыл» сүзен «авыл җирлеге» сүзләренә алмаштырырга;

3 нче кушымта белән тулыландырырга (кушымта итеп бирелә);

4 нче кушымта белән тулыландырырга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының
17.12.2020 № 541-5/соц-2020
карарына 3 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының
№ ___________________________
карары редакциясендә)

## 2021 елга Татарстан Республикасы халыкка комплексլы социаль хезмәт күрсәтү үзәгенең һәм инвалидларны тернәкләндерү үзәгенең көндезге тору бүлекчәсендә социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучылар өчен күрсәтелә торган социаль хезмәтләр күрсәтүнең ярымстационар формасында күрсәтелә торган социаль хезмәтләргә тарифлар

| № | Социаль хезмәт күрсәтүче оешма төре | Социаль хезмәт күрсәтү формасы | Социаль хезмәтнең аталышы | Социаль хезмәткә тасвирлама | Хезмәт берәмлеге | Социаль хезмәт күрсәтүне финанслауның җан башына нормативы, сум | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | шәһәр җирлеге | авыл җирлеге |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| 1. | Халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәгенең, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләренең көндез килә торган бүлекчәсе | социаль хезмәтләрдән файдаланучылар өчен | | | | | |
| 1.1. | | ярымстационар форма | **социаль-көнкүреш хезмәтләре** | | | | |
| 1.1.1. | | | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслаган нормативларга туры китереп, йомшак инвентарь һәм санитар-гигиена билгеләнешендәге товарлар белән тәэмин итү | | 1 хезмәт | 11,33 | 11,33 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.1.2. | | | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслаган нормативларга туры китереп, социаль хезмәтләр күрсәтү өчен мәйданнар бирү | | 1 хезмәт | 132,27 | 132,27 |
| 1.2. | | | **социаль-медицина хезмәтләре** | | | | |
| 1.2.1. | | | социаль-медицина мәсьәләләре буенча консультацияләү | | 1 хезмәт | 516,05 | 539,95 |
| 1.2.2. | | | сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруга юнәлдерелгән чаралар уздыру | | 1 чара | 688,00 | 720,00 |
| 1.2.3. | | | савыктыру чараларын уздыру | | 1 чара | 24,19 | 25,31 |
| 1.3. | | | **социаль-психологик хезмәтләр** | | | | |
| 1.3.1. | | | социаль-психологик консультация бирү | | 1 чара | 237,99 | 237,99 |
| 1.4. | | | социаль-педагогик хезмәтләр | | | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.4.1. | | | социаль-педагогик коррекцияләү, диагностиканы һәм консультацияләүне дә кертеп | | 1 чаралар комплексы | 82,06 | 87,15 |
| 1.4.2. | | | уңай мәнфәгатьләр формалаштыру | | 1 чаралар комплексы | 60,64 | 64,38 |
| 1.4.3. | | | ял вакытын оештыру | | 1 чаралар комплексы | 58,04 | 61,62 |
| 1.5. | | | **социаль-хокукый хезмәтләр** | | | | |
| 1.5.1. | | | юридик хезмәтләр алуда ярдәм күрсәтү | | 1 консультация | 555,52 | 555,52 |
| 1.6. | | | **социаль хезмәттән файдаланучы затның коммуникатив мөмкинлекләрен арттыру максатларында күрсәтелә торган хезмәтләр** | | | | |
| 1.6.1. | | | социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль-тернәкләндерү чаралары уздыру | | 1 чара | 140,69 | 147,21 |

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
17.12.2020 № 541-5/соц-2020
карарына 4 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
№ _________________________
карары редакциясендә)

## 2021 елга балигъ булмаганнар өчен социаль-тернәкләндерү үзәгендә социаль хезмәттән файдаланучылар өчен социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында күрсәтелә торган социаль хезмәтләргә тарифлар

| № | Социаль хезмәт күрсәтүче оешма төре | Социаль хезмәт күрсәтү формасы | Социаль хезмәтнең аталышы | Социаль хезмәткә тасвирлама | Хезмәт берәмлеге | Социаль хезмәт күрсәтүне финанслауның җан башына нормативы, сум |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | шәһәр җирлеге |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| 1. | Балигъ булмаганнар өчен социаль-тернәкләндерү үзәге | хезмәтләрдән файдаланучылар өчен | | | | |
| 1.1. | | стационар форма | **социаль-көнкүреш хезмәтләре** | | | |
| 1.1.1. | | | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслаган нормативларга туры китереп, торак урыннары мәйданнары бирү | | 1 хезмәт | 52,61 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.1.2. | | | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслаган нормативларга туры китереп, йомшак инвентарь һәм санитар-гигиена билгеләнешендәге товарлар белән тәэмин итү | | 1 хезмәт | 53,69 |
| 1.1.3. | | | медицина оешмаларына транспорт белән илтүне оештыру | | 1 хезмәт | 435,89 |
| 1.1.4. | | | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслаган нормаларга туры китереп, ризык белән тәэмин итү | | 1 хезмәт (4 тапкыр туклану) | 261,52 |
| 1.1.5. | | | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслаган нормативларга туры китереп, социаль хезмәтләр күрсәтү өчен мәйданнар бирү | | 1 хезмәт | 123,06 |
| 1.1.6. | | | сәламәтлек торышы буенча аларны мөстәкыйль рәвештә башкара алмаган затларга гигиена хезмәтләре күрсәтү | | 1 хезмәт | 21,55 |
| 1.1.7. | | | ашарга (ашатырга) булышу | | 1 хезмәт (4 тапкыр туклану) | 21,55 |
| 1.1.8. | | | торак урыннарны җыештыру | | 1 хезмәт (чаралар комплексы) | 8,74 |
| 1.2. | | | **социаль-медицина хезмәтләре** | | | |
| 1.2.1. | | | социаль хезмәтләрне алучыларның сәламәтлеге буенча торышын күзәтүгә бәйле процедураларны башкару | | 1 хезмәт (процедуралар комплексы) | 38,28 |
| 1.2.2. | | | савыктыру чараларын уздыру | | 1 хезмәт | 15,85 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.2.3. | | | сәламәтлекләре буенча торышларында җитешсезлекләрне ачыклау максатында социаль хезмәтләр алучыларны системалы рәвештә күзәтү | | 1 хезмәт (караулар комплексы) | 55,51 |
| 1.2.4. | | | социаль-медицина мәсьәләләре буенча консультацияләү | | 1 консультация | 961,87 |
| 1.2.5. | | | табиб тарафыннан медицина каравын уздыру | | 1 карау | 92,69 |
| 1.2.6. | | | табиб билгеләмәсе буенча медицина процедуралары уздыру | | 1 хезмәт | 721,33 |
| 1.2.7. | | | сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруга юнәлдерелгән чаралар уздыру | | 1 чара | 745,44 |
| 1.3. | | | **социаль-психологик хезмәтләр** | | | |
| 1.3.1. | | | социаль-психологик консультацияләү, шул исәптән гаиләдәге мөнәсәбәтләргә кагылышлы мәсьәләләрдә | | 1 консультация | 456,27 |
| 1.4. | | | **социаль-педагогик хезмәтләр** | | | |
| 1.4.1. | | | социаль-педагогик коррекцияләү, диагностиканы һәм консультацияләүне дә кертеп | | 1 хезмәт (чаралар комплексы) | 1184,21 |
| 1.4.2. | | | уңай мәнфәгатьләр формалаштыру | | 1 хезмәт (чаралар комплексы) | 376,86 |
| 1.4.3. | | | ял вакытын оештыру | | 1 хезмәт (чаралар комплексы) | 209,32 |
| 1.5. | | | **социаль-хезмәт хезмәтләре** | | | |
| 1.5.1. | | | хезмәт мөмкинлекләреннән файдалану һәм мөмкин булган һөнәри күнекмәләргә укыту буенча чаралар уздыру | | 1 хезмәт | 124,64 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.5.2. | | | эшкә урнашырга ярдәм итү | | 1 хезмәт | 1619,80 |
| 1.6. | | | **социаль-хокукый хезмәтләр** | | | |
| 1.6.1. | | | юридик хезмәтләр алуда ярдәм күрсәтү | | 1 хезмәт | 1673,19 |
| 1.6.2. | | | документларны рәсмиләштерүдә һәм торгызуда ярдәм күрсәтү | | 1 хезмәт (чаралар комплексы) | 1673,19 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге